**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясе турында» 2012 елның 9 октябрендәге ПУ-862 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 22 июнендәге ПУ-570 номерлы, 2017 елның 1 июлендәге ПУ-596 номерлы һәм 2019 елның 25 маендагы ПУ-298 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Ф.С. Габделганиевны, А.А. Кондратьеваны, О.Г. Синяшинны, В.Е. Туманинны, Г.Л. Удачинаны, Р.А. Шәйхетдиновны, С.В. Юшконы чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Баталов Никита Андреевичны – «Татарстан Республикасының Иҗади яшьләр академиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президентын (килешү буенча);

Волынец Ирина Владимировнаны – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне (килешү буенча);

Казаков Юрий Михайловичны – Казан милли тикшеренү технология университеты ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны (килешү буенча);

Калачев Алексей Алексеевичны – Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге федераль тикшеренү үзәге директоры вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

Кареева Юлия Рөстәм кызын – Татарстан Республикасы Яшь галимнәр һәм белгечләрнең төбәк иҗтимагый яшьләр хәрәкәте Башкарма комитеты рәисен (килешү буенча);

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын, аны Совет рәисенең урынбасары итеп расларга;

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын;

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

Шмелева Елена Владимировнаны – «Талант һәм уңыш» мәгърифәти фонды җитәкчесен (килешү буенча);

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Т. Борһановның – «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча)»;

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

Н.Ө. Мәгановның – «В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 09 апрель
№ ПУ-278